**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“25” ноябрь 2022 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 25 ноябрендә “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-урам утларын яктырту максатыннан лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;

- авыл территориясен төзекләндерү (чүп уләннәрне чабу, чистарту), хезмәт өчен түләү.

- янгын гидранты һәм төзелеш материаллары сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү (Ленин урамында -2 шт.,Советская урамында-1 шт.,К.Маркс урамында – 1 шт. гидрантлар урнаштыру)

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаларны башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 183(бер йөз сиксән өч) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 93 (туксан өч ) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 93(туксан өч) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урам утларын яктырту максатыннан лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;
- авыл территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрне чабу, чистарту), хезмәт өчен түләү.
- янгын гидранты һәм төзелеш материаллары сатып алу, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү (Ленин урамында -2 шт.,Советская урамында-1 шт.,К.Маркс урамында – 1 шт. гидрантлар урнаштыру)

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаларны башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Күңгәр авыл җирлеге Советы
5 нче округ депутаты: Абдуллин Р.Х.